

2025 елнын 26 маенда Мордовия Республикасынын Темников, Атюрьево, Ельники районнарындагы татар торак пунктларына Татарстан Фәннәр академиясенен Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтынын фәнни хезмәткәрләре комплекслы экспедициясе старт алды.
Экспедиция составында фольклорчы Ильмир Ильдар улы Ямалтдинов - экспедиция житәкчесе; телче Альфия Карим кызы Булатова; музыка белгече Гульназ Гилфан кызы Гилемьянова; сәнгать белгече Людмила Михайловна Шкляева; археограф Ләйлә Шамиль кызы Гарипова; эпиграфист Венер Мударис улы Усманов. Алтынчы июньгә кадәр аларга Мордовия Республикасында яшәvче татарларнын рухи һәм язма мирасын, матди һәм традицион музыкаль мәдәниятен, халык сәнгатен жыю һәм ойрәнv белән шогыльләнергә туры киләчәк.
Шулай, 2025 елнын 27 маенда Темников районы Тархан авылы клубында Галимжан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтынын фәнни хезмәткәрләре торкеме булган. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,



сәнгать, фольклор, диалектология, археография һәм эпиография буенча комплекслы экспедиция кысаларында, әлеге районнын Тархан, Енаково белән Акашево авыллары халкы белән дә аралашканнар һәм жирле халыкнын конкvреше, гореф-гадәтләре турында бик кvп кызыклы нәрсәләр туплаганнар.
Икенче конне, ягъни 28 майда “Аксельский” мәдәният йорты белән китапханә хезмәткәрләре, галимнәр белән бергә, Дашкино һәм Татар Адаево авылларында булганнар. Экспедициядә катнашучылар жирле татарларнын борынгы гореф-гадәтләре турында материал туплаганнар. Татар Адае авылында яшәvче Шамиль Халим улы Ялышев баянга, гармунга кушылып, бик кvп борынгы жырлар жырлаган һәм авылы халкы белгән хикәяләрне сойләгән.
2025 елнын 29 маенда Татарстан галимнәре шул ук районнын Митрялы авылы халкы белән аралашканнар: Ряшидә Ибраһим кызы белән тормыш иптәше Халим Алим улы Ялышевлар, татарларга хас похтә, кунакчыл ойләрендә сакланып калган борынгы китаплар



турында кvп яналыклар ишеттергәннәр, ә галимнәр - язып алганнар. Ә Камиль Зәгидулла улы белән Садия Зәйдулла кызы Шехмаметьевлар жылы, кунакчыл ойләрендә хужабикә Садия ханым, Сания Ахмәдулла кызы Урусова белән Венера Рәшит кызы Ялышева башкаруларында борынгы татар жырларын, такмакларын башкарганнар, экспедициячеләр - материалларны туплап алганнар. Казанлылар Митрялы авылы китапханә музее материаллары белән дә танышканнар һәм татар телендә нәшерләнгән китапларын китапханәгә бvләк иткәннәр.

Казан галимнәренен оч тапкыр Мордовиядәге экспедиция вакытында жиде авылнын зиратларын тикшерергә олгергән: Тарханы, Дашкино, Енаково, Сухово, Русское Тювеево, Большое Татарское Караево, Татарское Акашево. Дашкинода 1762 елгы бер иске таш табылган. Суховодан Хәлил абзый Сухов белән Олы Татар Караевосыннан Хәлил хәзрәт кабер ташларынын урыннарын кvрсәткәннәр. Венер Мударис улы Усманов, экспедиция кысаларында барысын ойрәнеп бетерә дә алмый. Бу бик четерекле һәм кvп хезмәт таләп иткән эш. Әйтеп китәргә кирәк, Темников районындагы Хан зиратында кимендә борынгы 10 таш була, шул исәптән 2 метр биеклектәгесе дә. Изге зират дип атала. Жирле халык анын урынын яхшы белә. Ул Тархан авылы белән Темников авылы арасындагы кырда урнашкан.
Татарстан Фәннәр академиясенен Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтынын фәнни хезмәткәрләре Мордовия татарлары яшәгән авылларда комплекслы экспедицияләрен дәвам итәләр.

**Наилә НАСЫРОВА**